| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАРАТЛЫ-КИЧУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРАТЛЫ-КИЧУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 10** **21.08.2026 ел**

"2026-2028 елларга Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең җирләреннән файдалану һәм саклау" муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауны тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 маддәсе, Россия Федерациясе Җир кодексының 11, 13 маддәләре, 06.10.2003 елдагы №131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законы, 28.07.2004 елдагы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Кануны нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. "2026-2028 елларга Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең җирләреннән файдалану һәм саклау" муниципаль программасын расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм саклау "Муниципаль программасын раслау турында" 2021 елның 9 июнендәге 11 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Вәлиев И.М

Татарстан
Республикасының Минзәлә
муниципаль районы Наратлы-
Кичү авыл жирлеге Башкарма
комитеты карарына кушымта
«21»август 2026 ел №10

**"2026-2028 елларга Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең җирләреннән файдалану һәм саклау" муниципаль программасы**

**2026-2028 елларга Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең җирләреннән файдалану һәм саклау буенча муниципаль программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигезләмә | РФ Җир кодексы, 06.10.2003 елдагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» N131-ФЗ Федераль законы |
| Заказ бирүче | Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның төп максаты | Наратлы-Кичү авыл җирлеге җирләрен саклау һәм рациональ куллану чараларын гамәлгә ашыру |
| Программаның билгеләнеше | Наратлы-Кичү авыл җирлеге җирләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2026-2028 еллар |
| Көтелгән нәтиҗәләр | Җирләрне саклау һәм рациональ куллану, бозылган җирләрне торгызу, халыкның экологик куркынычсызлыгын һәм яшәү сыйфатын күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру |
| Программаның гамәлгә ашырылуын контрольдә тоту | Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитеты |

1.Муниципаль программаны тормышка ашыру өлкәсендәге хәзерге

халәтнең сыйфатламасы һәм төп проблемалары

Җир - әйләнә-тирә мохитнең мөһим өлеше, аның кулланылышы башка барлык табигать объектлары: хайваннар, урманнар, үсемлекләр дөньясы, сулар, файдалы казылмалар һәм җир катламының башка кыйммәтләре белән бәйле. Җирне куллану һәм саклау булмаганда, башка табигый ресурсларны файдалану мөмкин түгел. Җиргә карата хуҗасызлык тиз арада зыян китерә яки якын киләчәктә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерәчәк, җир-туфрак өслеге катламының җимерелүенә генә түгел, ә аның химик һәм радиоактив пычрануына китерәчәк, шулай ук барлык табигый комплексның экологик начараюы белән дә барачак.

"2026-2028 елларга Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең җирләреннән файдалану һәм саклау" муниципаль программасы (алга таба - Программа) җирләрне куллану һәм саклауның уңайлы шартларын барлыкка китерүгә, икътисадыны ныгыту мәнфәгатьләрендә җир ресурсларын нәтиҗәле һәм рациональ файдалану һәм идарә итү дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Җир фондының төрле максатлар өчен зур күләмендә кулланылышы әйләнә-тирә мохит экосистемасының барлык буыннарының табигый бөтенлеген саклау буенча билгеле бурычларны куя. Табигатьтә барысы да үзара бәйле. Шуңа күрә звенонының бер буынының, бу урман, хайваннар дөньясы, җир булсын, дөрес эшләвен бозу экологик системаның балансын һәм бөтенлеген бозуга китерә.

Җирне рациональ булмаганча файдалану, аңа куллланучыларча һәм җавапсыз мөнәсәбәт аның башкарыла торган функцияләрен бозуга, табигый сыйфатларының түбәнәюенә китерә.

Җирне саклау, җирдән рациональ файдалану тәэмин ителгәндә генә, нәтиҗәле була ала.

Наратлы-Кичү авыл җирлегенең тотрыклы социаль-икътисадый үсеш проблемалары һәм аның халкының экологик куркынычсыз яшәү эшчәнлеге хәзерге этапта җирләрне саклау һәм куллану мәсьәләләрен хәл итү белән тыгыз бәйләнештә. Авыл җирлеге дәрәҗәсендә җирләрне саклау һәм куллануның урындагы проблемаларын мөстәкыйль, бөтен, комплекслы, зирәк акыл белән, биредә яшәүче кешеләрнең генә түгел, ә киләчәк буыннарның мәнфәгатьләрен дә күздә тотып, хәл итәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителгән төрле кулланыштагы җир кишәрлекләре бар.

Иң кыйммәтлеләре авыл хуҗалыгы җирләренә караган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр санала.

Җирлек территориясендәге көтүлекләр үзләренең мәдәни-техник халәте буенча нигездә чиста. Көтүлекләр шәхси ярдәмче хуҗалыклар тарафыннан кулланыла.

Көтүлек азыгын кулланучыларның барысын исәпкә алганда, табигый көтүлекләр көчле йөкләмә тоймый. Барлык көтүлекләрдә дә диярлек яшел үлән артыгы белән җитәрлек.

Җирләрнең экологик халәте уртача яхшы, ләкин стихияле рәвештә рөхсәт ителмәгән чүплекләр әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый һәм экологик ситуацияне начарлата.

## 2. Муниципаль программаның максатлары, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре, башкарылу вакыты һәм этаплары

Җирлек территориясендә җирләрне куллану һәм саклау өлкәсендәге муниципаль сәясәтнең төп принциплары: Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенең законлылыгы һәм ачыклыгы, җаваплылыгы һәм контроль астында булуы, нәтиҗәлелек.

Муниципаль программаның максатлары: пычратуны, ярлылануны, деградацияне, бозылуны, җирләрне һәм туфракларны юк итүне бетерү һәм булдырмау, шулай ук җирләргә һәм туфракларга башка тискәре йогынты тәэсир ителүне, шулай ук авыл хуҗалыгы җирләрендә туфракларның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен җирләрне рациональ куллануны тәэмин итү.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекне җайга салу;
- җирләрдән файдалану һәм саклауның нәтиҗәлелеген күтәрү, җирләрне рациональ куллану һәм саклауны оештыруны тәэмин итү;
- яшел үсентеләрне саклау һәм торгызу;
- җирләргә инвентаризацияләү үткәрү.

Җирләрне инвентаризацияләү деградацияне, пычратуны, чүпләүне, җирләрне бозуны, хуҗалык эшчәнлегенә башка тискәре йогынты тәэсир ителүне булдырмау, кулланылмаган, рациональ булмаганча кулланылган яки максатлы билгеләнеше буенча булмаган һәм рөхсәт ителгән кулланышка туры килмәгән җир кишәрлекләрен, җирләрнең башка характеристикаларын ачыклау өчен үткәрелә.

Әлеге программаны тормышка ашыру җирдән файдалануны тәртипкә салуга; яңа җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертүгә; авыл җирлекләренең

инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга, шуңа тәңгәл рәвештә икътисад үсешенә, җирләрдән нәтиҗәле файдалануга һәм саклауга булышачак.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр тәэмин ителәчәк:

1) Торак пунктларны төзекләндерү;

2) Җирләрнең сыйфат характеристикаларын яхшырту;

3) Җирләрдән нәтиҗәле файдалану.

Программаны тормышка ашыру вакыты - 2026-2028 еллар.

## 3.Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа чикләрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклауның нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар планлаштырылган.

| № т\б п | Чараларның атамасы | Финанслау чыганакларын күрсәтеп финанслау | Башкаручы | Башкару вакыты | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Чокырларның өске киселешләрен ныгыту | Оешмаларның, шәхси затларның, җир кулланучыларның үз акчалары | Җирнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 2. | Грунтның киң файдаланышта булган файдалы казылмалар карьерларын инвентаризацияләү үткәрү. Күрсәтелгән карьерларны билгеле оешмаларга | | Авыл авыл җирлегенең Башкарма комитеты | 2026-2028 | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | беркетеп бирү. Аларны рекультивацияләү проектларын эшләү. | | | | |
| 3. | Карьерларны рекультивацияләү | Оешмаларның, шәхси затларның, җир кулланучыларның үз акчалары | Карьерларда н файдалануч ылар | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 4. | Шәхси буаларны, гидротехник корылмаларның башка су объектларын ачыклау һәм бу корылмаларны билгеле биләүчеләре тарафыннан тикшерү | | Авыл җирлегенең Башкарма комитеты | 2026-2028 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 5. | Җирләргә куллану чикләрен салу, линияле корылмалар объектлары, юл челтәре, чикләнгән кулланылыштагы җирләр чикләрен куеп, җирләрнең бердәм мәгълүмат базасын формалаштыру һәм алып бару куллану, сыйфат күрсәткечләре | | Авыл җирлегенең Башкарма комитеты | 2026-2028 | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Наратлы-Кичү авыл җирлеге торак пунктлары территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү | 20000 сум | Авыл җирлегенең Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 7. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар басудан, чүп үләннәреннән һәм зарарлы органимнардан саклау чараларын үткәрү | Җир кулланучының үз акчалары | Җирнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 8. | Деградациягә, пычрануга, чүпләнүгә, башка тискәре (зарарлы) хуҗалык эшчәнлеге тәэсиренә дучар булган җирләрне яхшырту һәм торгызуны тәэмин итү | Җир кулланучының үз акчалары | Җирнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |